**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 10 октябрендәге 4292 номерлы карары**

## Яшь галимнәр арасында Е.К.Завойский исемендәге Казан премиясен алуга конкурс оештыру турында

Казан шәһәре Башкарма комитетының чаралар планын төгәлләштерү һәм яшь галимнәр арасында Е.К.Завойский исемендәге Казан премиясен алуга конкурсның стипендия фонды артуга бәйле рәвештә, Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасының яшь галимнәрен физика-математика фәннәре өлкәсендә тикшеренүләргә җәлеп итү һәм бу өлкәдә эшне камилләштерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Расларга:

1.1. Яшь галимнәр арасында Е.К.Завойский исемендәге Казан премиясенә конкурс турында нигезләмә (1 номерлы кушымта);

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты (А.Р.Заһидуллина) Казан шәһәренең яшь галимнәре арасында Е.К.Завойский исемендәге Казан премиясен алуга конкурсны оештыручы булып тора.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә (И.Р.Мөхәммәтшин), Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенең бюджет язмасында каралган ассигнованиеләрне «Яшьләр сәясәте» 0707 бүлеге, 99 0 00 43100 «Балалар һәм яшьләр өчен чаралар үткәрү» максатчан статьясы буенча тиешле күләмдә киметү хисабына, 2024 елда Казан шәһәренең яшь галимнәре арасында Е.К.Завойский исемендәге премияне түләүгә бәйле чыгымнарны үткәрү өчен, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетына ассигнованиеләрне 145 000,00 сум күләмендә арттырырга.

4. Тантаналы чараларны оештыруга, уздыруга һәм Казан шәһәренең яшь галимнәре арасында Е.К.Завойский исемендәге премияләрне түләүгә бәйле чыгымнарны Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре

комитетының тиешле финанс елына бюджет язмаларында каралган акчалар хисабына 265 000 сум күләмендә башкарырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 10 октябрендәге
4292 номерлы карары белән
расланды

# Яшь галимнәр арасында Е.К.Завойский исемендәге Казан премиясен алуга конкурс турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

Яшь галимнәр арасында Е.К.Завойский исемендәге Казан премиясен алуга конкурс (алга таба – Конкурс) Казан шәһәре Башкарма комитетының балалар һәм яшьләр эшләре комитеты тарафыннан Казан шәһәре (Идел буе) федераль университеты һәм Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-технология институты белән берлектә, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты каршындагы Казан шәһәренең яшь галимнәре һәм белгечләре советы катнашында үткәрелә.

## II. Максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс Казан шәһәре һәм Татарстан Республикасы аспирантларын һәм яшь галимнәрен физика-математика фәннәре өлкәсендә тикшеренүләргә җәлеп итү һәм бу өлкәдә эшне камилләштерү максатыннан уздырыла.

2.2. Конкурсның бурычлары:

- яшьләрнең фәнни-тикшеренү эше белән кызыксынучанлыгын арттыру;
- иң яхшы инновацион фәнни-тикшеренү эшләрен ачыклау һәм аларга булышлык күрсәтү;
- фәнни процесста катнашучылар арасында аралашу һәм тәҗрибә уртаклашу өчен мохит тудыру;
- инициативалы, талантлы яшьләрнең мәгълүматлар базасын булдыру;
- тикшеренү һәм җитештерү эшчәнлеге өчен кадрлар потенциалын формалаштыру;
- талантлы яшьләргә матди ярдәм күрсәтү.

## III. Катнашучыларның категорияләре һәм катнашу шартлары

3.1. Конкурста фәнни эшчәнлекләрен Казан шәһәрендә алып баручы, гариза бирү вакытына 35 яшькә кадәрге булган (аны да кертеп) югары уку йортларының һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләренең аспирантлары һәм яшь галимнәре катнаша ала.

3.2. Эшләр коллегиаль рәвештә институтларның президиумнары, секретариатлары, оешмаларның яки кафедраның фәнни советлары утырышларына чыгарыла.

3.3. Конкурста катнашуга кабул ителми:

- авторлар коллективлары;

- беренче урынны алган яки бүлешкән 2022-2023 еллар лауреатлары.

3.4. Конкурста оештыручыларның (Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты хезмәткәрләре), конкурс комиссиясе әгъзаларының катнашырга хокукы юк.

3.5. Конкурска тәкъдим ителә торган эшләр авторлык характерында булырга, элек басылып чыкмаска, конкурс максатларына һәм бурычларына җавап бирә торган төгәлләнгән оригиналь әсәрләр булырга тиеш.

3.6. Интернет челтәрендә булган материалдан файдалану тыела.

## IV. Гаризалар бирү тәртибе һәм формасы

4.1. Конкурста катнашу өчен Конкурста катнашучы 10 октябрьгә кадәр түбәндәге документларны тапшыра:

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (2 номерлы кушымта);

- Конкурста катнашучы эшли торган оешмадан Конкурста катнашуга тәкъдим-рекомендация;

- катнашучыны Конкурска чыгару турында гыйльми совет яисә кафедра (бүлек, лаборатория) утырышлары беркетмәсеннән өземтә;

- Конкурста катнашучы турында мәгълүмат язылган билгеләнгән үрнәктәге анкета (1 номерлы кушымта);

- физик-математик тематикада мөстәкыйль рәвештә башкарылган эш;

- Конкурста катнашучының фәнни җитәкчесенең бәяләмәсе;

- эшнең аннотациясе (бер биттән артык түгел);

- Конкурста катнашучы тарафыннан элек бастырылган мәкаләләрнең исемлеге һәм күчермәләре;

- Конкурста катнашучының паспорты һәм салым түләүченең тәңгәлләштерү номерының күчермәләре.

4.2. Барлык материаллар да рус телендә Казан шәһәре Башкарма

комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының электрон почтасына kazankdm@yandex.ru электрон рәвештә тапшырыла. Хат темасында катнашучының фамилиясен, исемен, атасының исемен һәм уку йортының атамасын күрсәтергә кирәк.

4.3. Физик-математик тематикадагы мөстәкыйль башкарылган эш түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- тикшеренү проблемасына кыскача кереш, тикшеренү темасын ачык бәян итү;
- актуальлекне, максатларны, бурычларны (фәнни эшләр өчен – тикшеренү гипотезалары), яңалыкны, гамәли әһәмиятен формалаштыру;
- теманың теоретик яктан эшләнеше, файдаланылган әдәбият исемлеге;
- тикшеренүнең конкрет ысулларының фәнни текстлар өчен кулланыла торган кагыйдәләр нигезендә рәсмиләштерелгән тасвирламасы;
- күзәтүләрнең һәм экспериментларның үз нәтиҗәләрен аерым бәян итү, алар буенча фикер алышу һәм анализлау;
- үткәрелгән тикшеренүнең төп этапларын һәм аны тәшкил итүче өлешләрен күрсәтә торган иллюстрацион материал;
- автор позициясенең оригинальлеге (алынган нәтиҗәләргә үз карашы булу);
- нәтиҗәләрне гомумиләштерү һәм нәтиҗәләр формалаштыру.

4.4. Эш катгый рәвештә А4 форматындагы ак кәгазь битләрендә башкарыла. Юллар арасындагы интервал – бер ярым. 14 пт зурлыгындагы кара шрифт мәҗбүри. Шрифт тибы – Times New Roman. Кәгазь бите кырыенда калдырыла торган буш урыннар: уңнан – 1 см, сулдан – 3 см, астан һәм өстән – 2 см.

4.5. Эш бербөтен, логик яктан төгәлләнгән материалны тәшкил итәргә тиеш.

4.6. Тапшырыла торган эш күләме – кушымталарны кертмичә, машинкада бастырылган 10 биттән артык түгел.

## V. Конкурс комиссиясен төзү һәм эшләү тәртибе

5.1. Эшләрне карап тикшерү өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты вәкилләреннән, Казан шәһәренең физика-математика фәннәре өлкәсендә эшләүче югары белем бирү оешмалары һәм фәнни оешмалар хезмәткәрләреннән торган конкурс комиссиясе төзелә.

5.2. Конкурс комиссиясе составына комиссия рәисе, секретарь һәм

12 комиссия әгъзасы кирә.

5.2.1. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, шулай ук комиссия утырышларын үткәрү өчен җавап бирә.

5.2.2. Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе эшен оештыруны, шул исәптән гаризалар исемлеген формалаштыруны, карарлар төзүне, комиссия утырышы беркетмәсен алып баруны тәэмин итә.

5.3. Конкурс комиссиясе составы әлеге нигезләмәдә раслана (4 номерлы кушымта).

5.4. Конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итүне Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты башкара.

5.5. Конкурста катнашучыларга бәя бирү өчен Конкурс комиссиясе:

- катнашучы турында мәгълүмат булган анкеталарны карап тикшерә;
- һәр катнашучының эшен гадел бәяли;
- һәр катнашучының рейтингыннан чыгып Конкурска йомгак ясый.

5.6. Конкурста җиңүчеләрне һәм призерларны ачыклаганда тавышлар саны тигез булса, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып санала.

5.7. Конкурс комиссиясе үз көче белән һәм үз вәкаләтләре кысаларында тапшырылган материаллардагы мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерә. Конкурста катнашу өчен бирелгән гаризада ялган яки дөрес булмаган белешмәләр, шулай ук гамәлдәге законнарга каршы килә торган мәгълүмат ачыкланган очракта, мондый гаризалар карап тикшерелми.

5.8. Конкурс комиссиясе әгъзасының җиңүчене билгеләгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул конкурс комиссиясе утырышы башланганчы бу хакта конкурс комиссиясе рәисенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы конкурс комиссиясе утырышында катнашмый.

5.9. Конкурс комиссиясе утырышы, анда Комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала.

5.10. Конкурс комиссиясе карары катгый һәм үзгәртелми.

## VI. Конкурсны уздыру һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

6.1. Дәгъвачылар фәнни-гамәли конференция барышында үз эшләрен яклыйлар. Чыгыш вакыты – 10 минутка кадәр, конкурс комиссиясе сорауларына

җаваплар – 5 минутка кадәр.

6.2. Конкурсны үткәрү урыны һәм вакыты турында гариза бирүчеләргә анкетада күрсәтелгән элемтә номеры буенча биш календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

6.3. Конкурс 2024 елның 20 октябреннән 25 октябренә кадәр үткәрелә.

6.4. Конкурсның һәр катнашучысы буенча бәя һәрберсенә аерым куела һәм Конкурс комиссиясе әгъзасының шәхси бәяләү битендә куела.

6.5. Бәяләү кәгазе Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана (3 номерлы кушымта).

6.6. Бәяләү кәгазенең һәр критерие, конкурс комиссиясе әгъзасының ихтыяры буенча, 1 дән 5 баллга кадәр бәяләнә.

6.7. Катнашучының рейтингы Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасына тигез.

6.8. Конкурс комиссиясенең Конкурска йомгак ясау турында карары күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм Конкурс комиссиясе рәисе раслаган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Конкурс комиссиясе әгъзасы, Конкурс нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, беркетмәгә үзенең аерым фикерен кертә.

6.9. Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты 2024 елның 30 октябреннән дә соңга калмыйча Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм үзенең социаль челтәрләрендә (https://vk.com/kddm_kazan һәм https://t.me/kddmk) конкурс нәтиҗәләрен бастырып чыгара.

## VII. Катнашучыларны бүләкләү

7.1. Конкурста җиңүче, көмеш һәм бронза призерлар билгеләнә. Призерлар һәм җиңүчеләр санына эләкмәгән катнашучылар Конкурста катнашу турында грамоталар белән билгеләп үтелә.

7.2. Приз фонды:

- Конкурста җиңүче 100 000 сум (йөз мең сум) ала;
- Конкурсның көмеш призеры 75 000 сум (җитмеш биш мең сум) ала;
- Конкурсның бронза призеры 50 000 сум (илле мең сум) ала.

7.3. Премия бирү турындагы карарны конкурс комиссиясе экспертиза нәтиҗәләре буенча гади күпчелек тавыш белән кабул итә. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның расланган составының кимендә 2/3 се катнашса, хокуклы санала.

7.4. Конкурста бүләкләү һәм аңа йомгак ясау өчен барлык конкурсантлар

чакырыла. Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү һәм җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү 30 октябрьдә булачак. Бүләкләүне үткәрү урыны һәм вакыты турында гариза бирүчеләргә анкетада күрсәтелгән элемтә номеры буенча биш календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

7.5. Акчалата премия алу өчен җиңүче һәм призерлар, үзләрен җиңүче дип таныганнан соң 1 (бер) айдан да соңга калмыйча, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре буенча комитеты белән kazankddm@yandex.ru электрон почтасы аша элемтәгә керергә һәм акчалата премия алу өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматны тапшырырга тиеш: фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт күчермәсе, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык, салым органында исәпкә кую турындагы таныклыкның күчермәсе, кредит оешмасында ачылган, акча премиясе күчерелергә тиешле счетларның реквизитлары турында белешмәләр булган акча премиясен күчерү турындагы гариза. Гариза Конкурста җиңүче (призер) тарафыннан имзаланырга тиеш.

7.6. Е.К.Завойский исемендәге Казан премиясе яшь галимнәр арасында агымдагы елның 31 декабренә кадәр берьюлы бирелә.

7.7. Игълан иткән вакыттан соң бер ай вакыт узгач Конкурста җиңүченең (призерның) акчалата премияне сорап алмавы мондый җиңүчене (призерны) акчалата премия алу хокукыннан мәхрүм итә.

7.8. Конкурста җиңүчеләргә һәм призерларга билгеләнгән үрнәктәге махсус дипломнар тапшырыла.

---

Яшь галимнәр арасында
Е.К.Завойский исемендәге
Казан премиясен алуга конкурс
турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
Форма

**Яшь галимнәр арасында Е.К.Завойский исемендәге**
**Казан премиясен алуны дәгъвалаучының анкетасы**

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ______________________________________
2. Туган көне ________________________________________________________________
3. Эш урыны, вазифасы ______________________________________________________
_________________________________________________________________________
4. Тикшеренүләр өлкәсе ______________________________________________________
_________________________________________________________________________
5. Фәнни җитәкчесе _________________________________________________________
6. Ирешелгән уңышлар турында белешмәләр (басмалар исемлеге, конкурсларда, конференцияләрдә катнашу, гамәлгә кертү актлары һ.б.) _____________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
7. Йорт адресы ______________________________________________________________
8. Элемтә өчен телефон номеры _______________________________________________
9. Электрон почта ___________________________________________________________
10. Паспорт, теркәлү мәгълүматлары ___________________________________________
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
11. Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры ______________________________
12. Пенсия иминиятләштерүе турында таныклык номеры ______________________

Анкетаны тутыру вакыты ___________________
катнашучының шәхси имзасы ____________________________________________

Яшь галимнәр арасында
Е.К.Завойский исемендәге Казан
премиясен алуга конкурс турында
нигезләмәгә 2 номерлы кушымта
Форма

ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК

Мин, ______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

паспорт ___________ ____________________________________ тарафыннан бирелгән,
(сериясе, номеры) (кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)

теркәлү адресы: ______________________________________________________________
яшь галимнәр арасында Е.К.Завойский исемендәге Казан премиясен алуга Конкурста шәхси мәгълүматларның бары тик югарыда санап үтелгән категорияләренә генә караган шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалыгымны бирәм: фамилия, исем, атамның исеме; җенес; туган көн; шәхесне таныклый торган документның тибы; шәхесне таныклый торган документтагы мәгълүматлар; Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры һәм Пенсия иминиятләштерүе турында таныклык номеры турындагы мәгълүматлар; гражданлык.

Мин шәхси мәгълүматларны әлеге Конкурста катнашумны раслау максатыннан гына файдалануга, шулай ук әлеге нәтиҗәләр турындагы мәгълүматларны электрон чыганакларда саклауга ризалыгымны бирәм.

Әлеге ризалык, шәхси мәгълүматларны (чикләүләрсез) җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), файдалануны, мәгълүмат алмашу буенча гамәлләр кылу өчен өченче затларга тапшыруны, шәхси мәгълүматларның шәхси үзенчәлекләрен бетерүне, блоклауны, шулай ук Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган теләсә нинди башка гамәлләр башкаруны да кертеп, шәхси мәгълүматларыма карата югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәк булган гамәлләр кылу өчен минем тарафтан бирелә.

Конкурсны оештыручылар минем шәхси мәгълүматларымны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә автоматлаштырылмаган һәм автоматлаштырылган ысуллар белән эшкәртүгә гарантия бирүләре турында миңа хәбәр ителде.

Әлеге ризалык шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларына ирешкәнчегә кадәр яисә мәгълүматны саклау вакыты дәвамында гамәлдә булачак.

Әлеге ризалык минем язма гаризам буенча теләсә кайсы вакытта кире кайтарып алынырга мөмкин.

Мондый ризалыкны биргәндә, үз теләгем белән һәм үз мәнфәгатьләремдә эш итүемне раслыйм.

«____» ___________ 202__ ел _______________ /__________________/
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Яшь галимнәр арасында
Е.К.Завойский исемендәге
Казан премиясен алуга конкурс
турында нигезләмәгә
3 номерлы кушымта

**Урында эшләү этабының бәяләү кәгазе**

Эш авторы ____________________________________________________

Эшнең исеме _________________________________________________

| № т/б | Бәяләү критерие | Бәя (1 дән 5 баллга кадәр) | Ачыклама |
|---|---|---|---|
| 1 | Күрсәтелгән тикшеренү темасының актуальлеге | | |
| 2 | Проектта хәл ителә торган мәсьәләләрнең фәнни әһәмияте | | |
| 3 | Ысулларның һәм алымнарның яңалык дәрәҗәсе | | |
| 4 | Конкурс юнәлешенә туры килү | | |
| 5 | Куелган бурычның төгәллеге һәм аны үтәүнең сыйфаты, конкрет нәтиҗәләр, йомгаклар яки тәкъдимнәр булу | | |
| 6 | Эш нәтиҗәләрен гамәлдә куллану мөмкинлеге | | |
| **Бәяләрнең йомгаклау суммасы** | | | |

Комиссия әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме
___________________________________ Имзасы __________

Яшь галимнәр арасында
Е.К.Завойский исемендәге
Казан премиясен алуга
конкурс турында нигезләмәгә
4 номерлы кушымта

**Эксперт комиссиясе составы**

Эксперт комиссиясе рәисе – Заһидуллина Алия Рөстәм кызы – Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисе.

Эксперт комиссиясе секретаре – Гыйльфанова Алсу Заиф кызы – Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының мәгариф учреждениеләре һәм яшьләр оешмалары белән эшләү бүлеге башлыгы.

Эксперт комиссиясе әгъзалары:

1. Галиев Илгиз Гатуф улы – А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ (килешү буенча);
2. Гафуров Марат Ревгер улы – Казан (Идел буе) федераль университеты (килешү буенча);
3. Голенищев-Кутузов Александр Вадимович – Казан дәүләт энергетика университеты (килешү буенча);
4. Калачев Алексей Алексеевич – Россия фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәгендәге Федераль тикшеренү үзәге (килешү буенча);
5. Петухов Владимир Юрьевич – Россия Фәннәр академиясенең Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техника институты (килешү буенча);
6. Скирда Владимир Дмитриевич – Казан (Идел буе) федераль университеты (килешү буенча);
7. Таланов Юрий Иванович – Россия Фәннәр академиясенең Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техника институты (килешү буенча);
8. Таюрский Дмитрий Альберт улы – Казан (Идел буе) федераль университеты (килешү буенча);
9. Шәкүров Гыйльман Солтан улы – Россия Фәннәр академиясенең Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техника институты (килешү буенча);
10. Харинцев Сергей Сергеевич – Казан (Идел буе) федераль университеты (килешү буенча).